**Бөтендөнья татар когрессы**
**Түбән Кама шәһәре администрациясе**
**Бөтендөнья татар когрессының Түбән Кама бүлеге**
**“Россиянең татар авыллары” бөтенроссия җәмәгать оешмасы**
**Башкортостан Республикасының “Рамазан”**
**төрки милли-агарту үзәге**

Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына,
Татарстан Республикасының 100 еллыгына,
“Татнефть” җәмгыятенең 70 еллыгына багышлап,
Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтү
кысаларында уздырыла

**Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының**
**халык артисты Фән Вәлиәхмәтов иҗатына багышланган**
**“Үзем уйныйм, үзем җырлыйм!”**
**IV Бөтенроссия татар җырын башкаручылар конкурсының**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ




**Түбән Кама, 2020 ел**

**КИЛЕШЕНДЕ**
Бөтендөнья татар когрессы
башкарма комитеты җитәкчесе

_____________Р.З.Закиров

**РАСЛЫЙМ**
“Россиянең татар авыллары
бөтенроссия җәмәгать
оешмасы советы рәисе”

_______________Ф.Г.Галимов

## I.Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе территориясендә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, төрки халыкларның дуслыгын һәм рухи элемтәләрен ныгыту, татар халкының вокаль һәм музыкаль башкару культурасын саклап калу һәм үстерү, традицион халык уен коралларын пропагандалау, халык иҗатын үстерү, бер үк вакытта вокалчы һәммузыкантсәләте дә булган яңа талантларны ачу максатында, 2020 елның 26 апрелендә “Үзем уйныйм, үзем җырлыйм!” IV Бөтенроссия татар җырын башкаручылар конкурсыүткәрелә. УлТатарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының халык артисты Фән Вәлиәхмәтов иҗатына багышлана.

Конкурс Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгына, Татарстанның 100 еллыгына, “Татнефть” җәмгыятенең 70 еллыгына багышлана.

Конкурста Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең барлык татар милли-мәдәни оешмалары, шулай ук, якын һәм ерак чит илләрдәге татар милли-мәдәни һәм җәмәгать оешмаларының әгъзалары катнаша ала.

## II.Конкурсны оештыручылар

Конкурс Бөтендөнья татар конгрессы, Түбән Кама шәһәре администрациясе, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге, “Россиянең татаравыллары” бөтенроссия җәмәгать оешмасы, Башкортостан Республикасының “Рамазан” төрки милли-агарту үзәге тарафыннан оештырыла.

## III. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

Конкурсны әзерләү һәм үткәрү максатында, оештыру комитеты төзелә, анда кемнәр кертеләчәген конкурсны үткәрүчеоешмаларның җитәкчеләре хәл итә.

Оештыру комитеты җитәкчесе – композитор-башкаручы, Татарстанның атказанган артисты, Башкортостанның атказанган мәдәният хезмәткәре, хәйрияче бертуган Рәмиевләр исемендәге халыкара премия лауреаты,

Туймазы районының мактаулы гражданы, Башкортостанның “Рамазан” төрки милли-агарту үзәгенең идарә әгъзасы, “Россиянең татар авыллары” бөтенроссия җәмәгать оешмасы рәисе Фәнир Гыйльметдин улы Галимов.

Оештыру комитеты гаризалар кабул итә, конкурста катнашучылар белән әзерлек эше алып бара, жюри әгъзаларын һәм рәисен билгели.

Конкурска 55 яшькә кадәрге үзешчән артистлар кертелә. Башкаручылар ике төрле яшь категориясендә ярыштырыла: 17 яшькә кадәргеләр һәм 18-55 яшьтәгеләр.

Конкурста катнашырга теләүчеләр 2020 елның 10 апреленә кадәр, электрон почта аша, тиешле үрнәк буенча гариза-анкета, персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкһәм үзләре тәкъдим итә торган ике җыр видеоязмасын җибәрергә тиеш.

Конкурс ике турдан тора. Беренче тур, җибәрелгән видеоязмалар буенча, 11 апрельгә кадәр үткәрелә. Беренче тур йомгаклары буенча жюри карары конкурста катнашучыга электрон почта аша хәбәр ителә.

Беренче турны уңышлы узган катнашучылар, икенче турда катнашу өчен, Түбән Кама шәһәренә чакырыла. Башкарылачак әсәрне конкурс алдыннан алмаштыру рөхсәт ителми. Программада үзгәреш булган очракта, конкурска кадәр өч көн алдан оештыру комитетына хәбәр итәргә кирәк (гариза үрнәге теркәлә).

Конкурсның һәр турында катнашучы, үзе тальянда яки башка ике рәтле гармунда уйнап ике җыр, бер татар халык җырын, бер татар авторының җырын башкарырга тиеш. Җырлар кабатлану рөхсәт ителә. Чыгыш өчен өстәмә аккомпаниатор яки ансабль (баяннан һәм аккордеоннан кала, халык уен кораллары) җәлеп итәргә дә ярый.

Классик һәм электрон музыка уен коралларын, шулай ук, “минусовка”ларны куллану рөхсәт ителми. Сәхнәдә микрофон була.

## IV.Бәяләү билгеләре

Конкурста катнашучыларның чыгышлары түбәндәге билгеләр буенча бәяләнәчәк:

- башкару осталыгы;
- үзенчәлекле башкару;
- сәхнә культурасы;
- башкаларны кабатламау;
- милли костюмның конкурс шартларына туры килүе.

Жюри карары яңадан тикшерелми һәм үзгәртелми.

Конкурс йомаклары Гала-концертта игълан ителә. Конкурста җиңүчеләр өч концертта – Казан, Уфа һәм Түбән Кама шәһәрләрендә бушлай чыгыш ясарга бурычлы.

## V.Конкурсны финанслау

Конкурсны җәмәгать оешмаларыһәм оештыру комитеты финанслый.

Катнашучылар конкурс фондына оештыру взносы түләми. Командировка чыгымнарын конкурста катнашучылар үзләре яки аларны җибәрүче оешмалар түли.

## VI.Җиңучеләрне бүләкләү

Һәр яшь категориясендә беренче, икенче һәм өченче урыннар билгеләнә.Конкурсның иң зур призы – Гран-при.

Оешмалар һәм спонсорлар үзләренең өстәмә призларын тәгъдим итә ала, алар оештыру комитеты һәм жюри белән килештерелергә тиеш.

Жюриның Гран-при бүләген һәм аерым призларны бирмәскә, шулай ук, призлы урыннарны җиңүчеләр арасында бүлергә дә хакы бар.

Татар җыр фольклорының сирәк булган әсәрен башкарган өчен махсус приз бирү каралган.

Жюриның башка махсус призлар бирергә дә хокукы бар.

## VII.Конкурс жюрие

Жюри рәисе – Татарстанның һәм Башкортостанның халык артисты Фән Гавис улы Вәлиәхмәтов.

Жюри әгъзалары:

1.Композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Тимершәех улы Закиров.

2.Татарстанның халык артисты, Башкортостанның атказанган артисты, филология фәннәре кандидаты Марат Сабит улы Шәрипов.

3.Татарстанның атказанган артисты, Башкортостанның атказанган мәдәният хезмәткәре, “Россиянең татар авыллары” бөтенроссия җәмәгать оешмасы рәисе Фәнир Гыйльметдин улы Галимов.

4.Бөтендонья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Марс Рифкать улы Тукаев.

## VIII. Элемтәгә керү өчен

Конкурста катнашучылар турында мәгълүматлар һәм аларның әзерләгән әсәрләре (1нче кушымта) электрон вариантта түбәндәге адреска кабул итә:fankonkurs20@mail.ru; fanirga@mail.ru

Белешү өчен телефоннар:

8-927-307-42-12 (Туймазы шәһәрендә),

8-927-354-13-32 (Уфа шәһәрендә).

**1нче кушымта**

**Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасыныңхалык артисты Фән Вәлиәхмәтов иҗатына багышланган “Үзем уйным, үзем җырлыйм!” IV Бөтенроссия татар җырын башкаручылар конкурсында катнашу өчен**

**гариза**

Катнашучының исеме, фамилиясе, атасының исеме____________________

Туган елы һәм көне_____________________________

Өй адресы______________________________________

Элемтә өчен телефоны__________________________

Электрон адресы________________________________

Кайда укый яки эшли___________________________

Башкара торган программасы (авторларын күрсәтеп), һәр әсәрнең хронометражы һәм гомуми яңгырау вакыты___________________________________

Өстәмә аккомпаниаторлары булса, исем - фамилиясе һәм атасының исеме, нинди уен коралында уйнавы________________________________________

Җырны нинди музыка уен коралында уйнап башкара_________________________________________________________________

Кыскача биографиясе_______________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Музыка уен коралларында  ничә яшендә уйный башлаган_____________

_____________________________________________________________________

Нинди җырларны тыңларга ярата___________________________________

_____________________________________________________________________

**2нче кушымта**

**“Үзем уйныйм, үзем җырлыйм!” IV Бөтенроссия татар җырын башкаручылар конкурсында катнашучының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы**

Фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)______________________

_____________________________________________________________________

Паспорт сериясе һәм номеры_________________________________________

Паспорт кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән__________________________

Теркәлгән адресы (паспорт буенча)____________________________________

_____________________________________________________________________

Персональ мәгълүматларсубъекты (алга таба – субъект) – катнашучы үзе.

Персональ мәгълүматлар операторы (алга таба - оператор) – конкурсның оештыру комитеты.

“Үзем уйныйм, үзем җырлыйм!” конкурсы (алга таба – конкурс).

“Персональ мәгълүматлар турында”гы Федераль закон (27.07.2006, №152-ФЗ) нигезендә, субъект операторга үзенең персональмәгълүматларын эшкәртергә рөхсәт бирә. Моңа мәгълүматларны җыю, язып алу, системага салу, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), алып файдалану, кая да булса тапшыру (тарату), алып ташлау, юкка чыгару хокукы да керә. Операторга мондый рөхсәт конкурсны оештыру, үткәрү һәм аңа йомгак ясау максатында бирелә. Субъект операторга үзенең персональмәгълүматларын, шулай ук конкурс өчен башкарган эшен массакүләм мәгълүмат чараларына, шул исәптән, интернетка тапшыру өчен ризалык бирә. Мондый ризалык түбәндәге персональмәгълүматларга кагыла: субъектның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, шәхесен раслый торган документ мәгълүматлары, яшәү адресы, туган елы, җенесе, телефоны, конкурста катнашу нәтиҗәсе (шул исәптән, конкурска әзерләгән эше), шулай ук, субъектның шәхесенә кагылышлы, операторга кирәкле булган башка информация. Бу килешүнең гамәлдә булу срогы – кул куелганнан соң өч ел. Субъект әзерләгән эшләрдән файдалану – сроксыз. Бу ризалыгын субъект, РФ закончалыгы нигезендә, язмача тәртиптә кире алырга мөмкин.

Катнашучы:

“__”_______________2020ел.            Имза__________/_______________/